ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.02.2024 п.г.т.Алексеевское № 47

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына керүче инвалидлар яшәгән күп фатирлы йортларда инвалидларның торак биналарын һәм гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясы, «Инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алып, күпфатирлы йортта торак урыннарны һәм гомуми милекне җайлаштыру чаралары турында» 2016 елның 09 июлендәге 649 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының 06.02.2017 № 21/о «Муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына керүче инвалидлар яшәгән күп фатирлы йортларда инвалидларның торак биналарын һәм гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү һәм эш тәртибен раслау турында» боерыгы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына керүче инвалидлар яшәгән күп фатирлы йортларда инвалидларның торак биналарын һәм гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзергә һәм составын расларга(Кушымта).
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында аларны инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру һәм аларның инвалидлар өчен уңайлылык шартларын тәэмин итү максатыннан муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына керүче инвалидлар яшәгән күп фатирлы йортларда инвалидларның торак биналарын һәм гомуми милекне

тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында» 2017 елның 13 февралендәге 52 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **М.Р. Гайсин**

Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
08.02.2024 № 47
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына керүче инвалидлар яшәгән күп фатирлы йортларда инвалидларның торак биналарын һәм гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль комиссия**
**Составы**

| | |
|---|---|
| Хәмзина Г.А. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе; |
| _______________ | Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Семина М.А. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алексеевск районындагы халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге директоры, комиссия секретаре( килештерү буенча); |
| Солдатова М.А. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алексеевск муниципаль районында социаль яклау бүлеге башлыгы (килештерү буенча); |
| Фомина Н.А. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы, комиссия секретаре; |
| Богатов Н.А. | «Управляющая компания» ҖЧҖ директоры (килештерү буенча); |
| Свистунова А.М. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы |
| Вильданов И.Х. | «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССОның баш табибы (килештерү буенча); |
| Сөләйманов Р.Б. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт, туризм һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча профилактика бүлеге башлыгы; |
| _______________ | Татарстан Республикасы Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең татар республика оешмасы иҗтимагый оешмасының Алексеевск район оешмасы рәисе (килештерү буенча); |

_______________ Алексеевск муниципаль районы шәһәр (авыл) жирлекләренең башкарма комитетлары житәкчеләре (килештерү буенча).

**Башкарма комитетының**
**Эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**